Салават күпере журналына кушымта

№2

Сыбызгы






Алсу Мингалимова

Уйларымны бүләк итәм












Алсу Мингалимовага хәзер 11 яшь. Ул Казандагы кызлар гимназиясендә укый. Сөйләшә башлаганчы ук рәсем ясарга тотынып шаккатырган кыз бу. «Сыбызгы»ның әлеге саны Алсуның рәсемнәреннән тора. Аңлатмалары да үзенеке.

«Салават күпере»
журналының
баш рәссамы
Фәрит Муллахмәт

Рәхмәт шайтаннарга!

Күрәсезме бу рәсемне?
Ә ул рәсем дә түгел, шулай мин язарга өйрәнә башладым. Хәзер алай язуны ташладым. Чөнки аны беркем дә танымый. Хәтта үзем дә танымыйм. Шайтаннар — таныйдыр. Алар өйрәткәндер мине шулай язарга.

Ә хәзер алар өйрәтә
һәм котырта мине
рәсем ясарга!
Рәхмәт инде үзләренә!
Мең-мең рәхмәт миннән шайтаннарга!





Аяксыз уйлар


Аяк киеме ясый белмәсәң,
аяк ясый белмәссең.
Аягын ясамагач,
килеп чыгар —
аяксыз рәсем.
Баш киеме ясый белмәсәң,
баш ясый белмәссең.
Башын ясамагач,
килеп чыгар —
башсыз рәсем.
Кыскасы,
рәсем ясарга тотынсаң,
шуны да бел:
һәр рәссамга баш кирәк,
һәр рәсемгә
баш кирәк түгел.
Аяк та —
һәр нәрсәгә кирәк түгел.
Мәсәлән, менә —
мин аяксыз уйлар уйлап
утырам ич бүген.












Рәссам буласың киләме?

Әгәр бик тә, бик тә, бик тә
рәссам буласың килсә —
син булырсың!
Зур булырсың!
Зур дөньяга танылырсың!
Ләкин, дустым,
зур булырга,
танылырга өйрәнгәндә:
килеп чыгар
менә шундый
«хәлсез», «мескен»
рәсемнәр дә.




Сандугач баласы

Зур сандугач түгел инде,
бу сандугач баласы.
Очып килгән,
арып килгән
һәм тора көчкә басып.

Канаты — калтырап тора,
койрыгы — уйнап тора.
Ә үзе, үзе барыбер —
фил колагына нәрсәдер
сайрарга уйлап тора.

Исемсез машина




Аптыраган төлкеләр,
аптыраган бүреләр:
— Кара-кара, куяннар!
— Машинада йөриләр!


Авылларны, шәһәрләрне
шаккатырып үтәләр.
Машинаның мондые —
булганы юк бит әле.

Дөбер-шатыр йөрми ул,
чыгармый ул төтен дә.
Бу машина исемен —
белми әле беркем дә.



Үзсүзле курчак





— Әй, апа! Телевизор эшләп торган чакларда, ярамый бит йокларга! — дип чыелдаган бу кызга курчагы. Кыз уянмаган. Уенчыгы икенче кат шулай чыелдаган. Кыз уянмаган. Бу үзсүзле уенчык. Өченче кат ул тагын да ныграк чыелдаячак, һәм апасы уяначак.

Кем шуны белә?

Дүрт бәбкә күрдем. Аларның берсе нидер тапты да капты. Икесе ашарга йөгерде. Ә берсе — иң кечкенәсе:


— Их, тизрәк зур каз булырга иде! — диде миңа карап.

— Ялгышасың, яшь бәбкә! – дидем мин аңа.

— Ялгышмыйм! — диде яшь бәбкә.

Яшь бәбкә дөрес әйттеме? Мин дөрес әйттемме әллә? Шуны кем белә?






Чәчәк яратучылар



Көтмәгәндә әллә каян
бер туп тәгәрәп килгән:
– Чәчәк яратучыларга
туплардан сәлам! — дип
ике гөмбә кычкырган.
Авызсыз да тавышсыз төп
нидер уйлап утырган.



Ә бу карга баласы кайда икән анасы?




Аргы ярга — кунакка!



Песинең туган көне



Бу песи туган көнне —
ике яшь тулган көнне
кошлар да бәйрәм иткән,
тычкан да бәйрәм иткән.
Шуңа песи шаккаткан
һәм
ялгыш
сөтен түккән.



Колак алкалары — алтын!

Бу хатын —
Тычкан исемле хатын.
Беләзеге — көмештән,
төймәләре — гәрәбә.
Колак алкалары — алтын,
һәм балалары — алтын!



Эш беткәч, йокларга ярый.





Укый белүче тычкан

— Кешеләр укыганда,
ник безгә укымаска?! —
дип кычкырды бер тычкан
һәм сызгырды ул тычкан!
— Менә килеп тә җиттек,
без тычканны ишеттек.
— Эчке якта, әй, кем анда?
Тиз ачыгыз ишекне!
— «Ачык» дигән сүзне дә
укый белми шул болар...
— Әнә, Тычкан үзе килә! —
Хәзер ишекне ачар.

Елак булса...


— Әнкәй,
кайчан алып кайтасың?
Энекәш булса да ярый,
сеңлекәш булса да ярый,
елак кына булмасын!
...Алып кайт
нинди булса да,
елак булса аны без...
Күп еласа аны без —
Үзебезнең депутатка,
язучы Роберт абыйга —
Миңнуллинга бирербез!





Байлык





Көзге

— Рәхмәт инде сезгә,
миңа килгәнегезгә.
Бик тә җитез икәнсез,
иртүк килеп җиткәнсез.
Менә сезгә көзге,
күрегез үзегезне:
сезнең кебек матурлар
беркайда да юк алар!



Малай, апа һәм абый

Кайчандыр —
бик күптән, бик күптән,
мин рәсем ясарга
өйрәнгән чакта,
тырышып-озаклап эшләргә
иренгән чакта —
шушы малайны ясадым.
Малай янына шушы апаны ясадым.
Алар янына абыйны
ясый башладым.
...Ләкин, ләкин абый рәсемен
төгәлләмәдем,
чөнки апа
эшем өчен
акча түләмәде.



Алсу Мингалимова:

Рәсем ясаганда мин үз теләкләремә ирешәм сыман. Мин сәяхәт итәргә теләсәм, сәяхәт итәм. Мультик карыйсым килсә — үз рәсемем мультик. Мин үз рәсемнәремдә күкләрдә очам, җәнлекләр белән сөйләшәм. Кайчакта патшабикә булып алам. Рәсем ясаган чакта аюга, тычканга, тылсымчыга, кошларга... әверелә алам. Рәсемнәрем аша мин әкияткә юл алам...

Укытучыларым

Чырык-чырык чыпчыклардай
килгән идек мәктәпкә.
— Укытучылар! — сүзен дә
белгән идек, әлбәттә.

Укый торгач, шуны белдек,
алар зур тылсымчылар.
Безнең кебек чыпчыклардан
Сандугач ясаучылар.

Сыбызгы

2 – 1999

«Салават күпере» журналына кушымта

Баш мөхәррир **Зиннур ХӨСНИЯР**
Баш мөхәррир урынбасары Фирая БӘДРЕТДИН
Бүлек мөхәррире Ләбиб ЛЕРОН
Бизәлеш мөхәррире Диләрә НӘУРУЗОВА
Компьютер дизайны Мөнирә КУЗИЕВА
Исәп-хисап бүлеге Рәмзия САЛИХ

Редакция адресы: 420012 Казан шәһәре, Мөштәри урамы, 14 нче йорт.
«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды
һәм төсләргә бүленде.
Татарстан газета-журналлар нәшрияты. Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Производствога бирелде 26.11.99 ел. Басарга кул куелды 26.11.99 ел.
Тиражы 12707 данә. Заказ 3-598. Бәясе килешү буенча.